Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы ш.т. Б. Сабасы гомуми үсеш бирүче төрдәге 5 номерлы “Бәләкәч” балалар бакчасы мәктәпкәчә белем бирү учреждениясе

# *“Нечкәбил”*
# мәктәпкәчә яшьтәге балалар өчен сәхнәләштерелгән музыкаль әкият

Автор: Яруллина Гөлия Дамир кызы,
тәрбияче

**2019 ел**

*(музыка)*
**А.б.:**Бар җиһанны нурга күмеп, бөтен тирә-юньне яктыртып офыкта алтын кояш күтәрелә. Кояш нурлары ямьле бакчага да сибелә. Бакчадагы бар тереклек җанлана.
*(кошлар, бөҗәкләр тавышы)*
**Кояш**: Иртүк торып сәлам бирәм,
Елмаеп таң аттырам.
Якты нурларымны сибеп
Барыгызны уятам.
Торыгыз, торыгыз, эшкә тотыныгыз.
**А.б.:**Күрәсезме, балалар, бакчабызда нindидер өйләр бар. Нинди өйләр икән соң алар?
**Балалар**: бал кортларының өйләре, умарталар.
**А.б.:**Кояш югары күтәрелгәч бал кортлары җиң сызганып эшкә тотыналар. Балалар, ә бакчада ничә йорт бар?
**Балалар:** өч.
**А.б.:**Ә бу йортлар бер-берсенә ошаганнармы?
**Балалар:** юк.
**А.б.:**Ничек аерылып торалар соң алар бер-берсеннән?
**Балалар:**Төсләре белән, бер йорт зәңгәр төстә.
**А.б.:**Әйе, бу зәңгәр йортта бик күп бал кортлары яши. Шулар арасында иң иртә торучы, иң уңган, иң акыллы бал корты - Нечкәбил дә яши икән.
**Нечкәбил:** Б-з-з, минем йорт күк төсле зәңгәр. Сау бул, өйкәем, матур гөлкәем. *(чәчәкләр арасында "очып" йөри)* Ах, нинди тәмле, нинди хуш исле чәчәкләр.
*(чәчәкләр биюе)*
**А.б.:** Нечкәбил чәчәктән чәчәккә кунып татлы сулар эчеп йөргәндә аңа саранча очрады:
**Саранча:** Әй, йонтач.
**Нечкәбил**: Минем исемем Нечкәбил, сүзең булса якын кил.
**Саранча:** Түзәр хәлем калмады. Кешеләр безне агулап үтерәләр, шомырт түшле сыерчыклар безне чүпләп кенә торалар.
**Нечкәбил:** Кешеләргә файда китерсәң, игеннәргә зыян салмасаң, сиңа берсе дә тимәс. Җылы өй ясап үрчетерләр, тәмле ширбәт эчертеп үстерерләр.
**А.б.:**Нәкъ шул вакытта һавада сыерчыклар күренде. *(сыерчыклар саранчаны уратып алалар һәм алып чыгып китәләр)*
**Нечкәбил:** *(кул янап)* Менә шулай ул, зыян салып йөрсәң.*(чәчәктән чәчәккә очып уйнавын дәвам итә)*
**Озынборын:** Чага торган кортчык, минем янга килеп чык.
**Нечкәбил:** Минем исемем Нечкәбил, сүзең булса үзең кил.
**Озынборын:** *(елап)* Мине берсе дә яратмый. Кайсы кулы, кайсы койрыгы белән сугып үтерә. Мин кояш нурларыннан куркам, шуңа күрә яфрак астында качып утырам.
**Нечкәбил:** Син бит бөтен кешене тешлисең, канын эчәсең.

*(Озынборын Нечкәбилнең сүзен тыңлап та бетерми, бакчада чүп утаучы кыз янына оча. Кыз аны куа китә. Нечкәбил бик борчылып алар артыннан карап кала. Ул чәчәкләр арасында уйнап йөрүен дәвам итә. Кемдер аңа калын тавыш белән эндәшә)*

**Кигәвен:** Бал корты, бал корты.

**Нечкәбил:** Минем исемем Нечкәбил, сүзең булса монда кил.

*(Үлән арасыннан выжылдау ишетелә. Ике аяклы, яшел башлы, күгелҗем кашлы кигәвен Нечкәбил янына килеп куна да зарланырга тотына)*

**Кигәвен:** Мин печән чабу вакытын бик көтәм. Элек кешеләр болында печән чабалар иде. Хәзер ниндидер зур машиналар килеп эшлиләр. Алар тирә-юньгә тәмсез ис тараталар, каты тавыш чыгаралар. Аларны тешләп тә булмый.

**Нечкәбил:** Ул машиналар трактор дип атала.

**Кигәвен:** Туктале, кеше исе килә, киттем әле мин шунда.

*(атлы егет чыбыркысы белән кигәвенне куа-куа чыгып китә, Нечкәбилнең кигәвенгә бик нык ачуы чыга)*

**А.б.:** Кинәт бик каты җил чыга, көньяктан күк күкрәп болыт та кузгала *(җил, күкрәү, янгыр тавышы)* Җил Нечкәбилне дә очыртып алып китмәкче була, ләкин ул карыша, җил белән тартыша.

**Нечкәбил:** Инде нишләргә?

**А.б.:**Нечкәбил аптырамый, агач астына кереп яшеренә.

*<u>Җыр “Янгыр ява”</u>*

*Яңгыр ява, уттай яна*
*Үләндәге тамчылар.*
*Салават күпере көлеп*
*Балкып тора каршыда.*

*Күбәләкләр коеналар*
*Ләйсән яңгыр яуганда,*
*Тамчыларга кушылып җырлыйм,*
*Чәчәкләр дә елмая.*

*Яңгыр яуганга шатлана*
*Безнең нәни дускайлар.*
*Кояш чыккач һич көттерми*
*Җырын сузар кошкайлар.*

*Агачлар да тыныч кына*
*Яңгыр үткәнен көтә,*
*Яфракларын җилфердәтеп*
*Алар да рәхмәт әйтә.*

**А.б.:**Җил болытларны куып тарата, яңгыр да тына, ялтырап кояш чыга. Нечкәбил дә өенә кайтырга чыга.

Алып кайткан балын кәрәз күзәнәгенә салыйм дисә ни күрсен: ятмәдән эшләнгән битлек кигән бабай, шундый ук битлекле бер малай умарталар янында йөриләр.

**Бабай :** Әйдә, улым, умарталарны карыйк. Бал кортлары балны күп җыйды микән?
**Малай:** Әйдә, бабай.
**Бабай:** Улым, әйдә төтенне өрдер әле. Балны карыйк.
**Нечкәбил:** Исәнме бабай, сәлам малай.
**Бабай**: Исәнме Нечкәбил.
**Нечкәбил:** Бабай, менә күпме бал җыйдым.
**Малай**: Ай-яй, күпме бал. Тәмләп бал белән чәй эчәрбез.
*Җыр "Ямьле җәй"*
*Ямьле җәй җитте менә,*
*Чыктык бакчага без дә,*
*Бергәләшеп уйнарбыз*
*Һич уеннан туймабыз.*

*Инештәге балыклар*
*Сикерешеп уйныйлар.*
*Яр буенда бакалар*
*Сәлам биреп калалар.*

*Зәңгәр күктә тургайлар,*
*Матур җырлар җырлыйлар.*
*Болын тулы җиләкләр*
*Эх, рәхәт тә шул җәйләр.*